Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**05.02. 2021 ел** **№28**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советының 2018 елның 4 июнендә кабул ителгән 92 номерлы «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә (2002 елның 13 мартындагы ред.), Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 4 июнендәге 92 номерлы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында Нигезләмә» 1 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 6,7,8 пунктлар өстәргә:

«6. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның еллык түләүле отпускы төп түләүле отпусктан һәм өстәмә түләүле отпусктан тора.

7. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен ел саен түләнә торган төп түләүле ялның озынлыгы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, ләкин 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

8. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпуск дәвамлылыгы муниципаль вазыйфа, муниципаль хезмәт вазыйфасы, шулай ук дәүләт вазыйфасы һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы ел саен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Ел саен бирелә торган төп түләүле отпуск һәм тиешле еллар эшләгән өчен ел саен өстәмә түләүле отпускның гомуми озынлыгы 45 календарь көненнән дә артмаска тиеш».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга. PRAVO.TATARSTAN.RU) Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы
поселогы Советы Рәисе Р.Ә. Кәримов